| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ** |

---

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Урта Камышлы<br>ав. | **КАРАР** |
| «08» февраль 2024 ел | | № 1 |

Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. . 2023 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Урта Камышлы авылы, Мәктәп урамы, 39нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү, элек расланганнарга өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 24.11.2023 ел, № 1 карарына;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 24.11.2023 ел, № 2 карарына.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Урта Камышлы авылында яшәүче гражданнар өчен тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы торак пунктында 24.11.2023 ел № 1 гражданнар җыены нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасы Нурлат

муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы торак пунктында 24.11.2023 ел № 2 гражданнар җыены карары турында алдан расланган карарга түбәндәге үзгәрешләр кертү белән килешәсезме:

2024 елда Урта Камышлы авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым тәртибендә алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлеген түбәндәге эш төрләре белән тулыландырырга:

- Зиратларны карап тоту;
- Урта Камышлы торак пункты чикләрендә поселок эчендәге һәм сезонлы юлларны ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Б. Храбров